*Күзләремне ачты минем,*
*Иркәләде үз телем.*
*Үз телем яктыртты юлны,*
*Үз телем бирде белем.*
*Үз телеңне сөймәгәндә,*
*Ярты ул алган белем,*
*Канатсыз коштай  буласың,*
*Белмәсәң ана телен*.

Гимназиябездә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын “Туган телләр була бер генә, туган телнең кадерен бел генә” дип исемләнгән әңгәмә белән башлап җибәрдек.  Әңгәмә барышында туган тел турында  шигырьләр, мәкальләр, гыйбрәтле сүзләр укылды. 9,10нчы сыйныф укучылары туган телгә карата үзләренең фикерләрен әйтте. Туган телгә кызыксыну уяту максатыннан ниләр эшләр идегез, дигән сорауга бик кызыклы җаваплар алдык.  Әңгәмә бик эчтәлекле, тәэсирле булды.



